وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№16 (133). 20 апрель 2012 / 29-җөмәдел-әүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



"Милли спорт төрләре милләтне саклап калырга ярдәм итә" ▷2 - 3◁



Исламиятнең бөек газизе ▷3◁



Дини мәгариф системасында мәдрәсә мөгаллиме эшчәнлегенең үзенчәлекләре ▷3 - 4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

МӘЧЕТКӘ АЙ КУЕЛДЫ

**18 апрель көнне Болгар комплексындагы мәчеткә алтын ай урнаштырылды.** Әлеге тантаналы чарада ТР Президентының социаль мәсьәләләр буенча ярдәмчесе, ТР Тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен торгызу буенча республика фонды оешмасының башкаручы директоры Татьяна Ларионова, Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Сергей Тюнев, Спас районы имам-мөхтәсибе Фәрхәт хәзрәт Минсәгыйров һәм районның дин әһелләре катнашты.

Манарага куелган айлар Казан шәһәренең "Арт Групп" ҖЧҖ предприятиесендә ясалган. Символларны манарага кую эшен дә Казанның "Гриф" ҖЧҖ альпинистлары башкарган.

**МӨСЕЛМАН ЯШЬЛӘРЕ СПАРТАКИАДАСЫ ҮТТЕ**

**Чирмешән районы үзәгендәге сәламәтләндерү комплексында мөселман яшьләре арасында спартакиада узды.** Район мөхтәсибәте тырышлыгы белән оештырылган ярышлар район яшьләрен генә түгел, күрше район вәкилләрен дә бер мәйданга җыйды. Мөселман яшьләре командаларга бүленеп, волейбол, мини-футбол, кул көрәше, йөзү, бау тарту һ.б. дисциплиналар буенча көч сынашкан. Катнашучыларның барысына да истәлекле бүләкләр тапшырылган.

"САБЫЙГА" АКЦИЯСЕ БАШЛАНДЫ!

**2012 елның 19 апреленнән алып агымдагы елның 1 июненә кадәр ТР мөселманнары Диния нәзарәте "Болгар" радиосы һәм Бөгелмә районы мөхтәсибәте белән берлектә, эти-әниләре ташлаган сабыйларга көндәлек кирәк-яраклар** (гигиена әйберләре, туклану катнашмалары һәм кечкенә бала киемнәре) җыю максатыннан, "Сабыйга" исемле хәйрия акциясе уздыра. Сабыйлар Бөгелмә районы балалар хастаханәсе каршында урнашкан "социаль койкалар"да сәламәтләндерү һәм тернәкләндерү курслары үтәчәк. Мондый курсларны алар 30 көн эчендә үтеп бетәргә тиеш, ләкин тормыш күрсәткәнчә, әлеге вакыт аралыгында гына моңа ирешеп булмый, шунлыктан, дәвалану берничә айга сузыла. Балаларны урнаштыру буенча аларның хокукларын кайгырту (опека) бүлеге шөгыльләнә, алар балага яңа эти-әни таба яки аны якындагы балалар йортына урнаштыру җаен карый. Уртача алганда, ай дәвамында балаларның "социаль койкалар"ыннан дистәгә якын сабый уза. Әлеге сабыйлар үзләренең эти-әниләре тарафыннан кире кагылсалар да, Җир йөзендә ярдәм кулы сузарга әзер торучы мәрхәмәтле кешеләр аз түгел. Барчагызны да сабыйларның гомеренә битараф калмаска чакырабыз.

Балаларга ярдәм итәргә теләүчеләр бала кирәк-яракларын ТР мөселманнары Диния нәзарәтенә китерә ала.

**Адресыбыз: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 йорт, 3 нче кат, 4 нче бүлмә, хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге.**

**Элемтә өчен телефон: +7 (843) 264-61-58 (Гөлнара Садыйкова).**

**Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды**

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

1 апрельдән алып 28 июньгә кадәр **2012 елның II яртыеллыгы** өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылырга мөмкин. 6 айга язылу бәясе - **118,38 сум**.

# "Казан басмасы"

**Россиядә Коръән басылуга 225 ел тулу уңаеннан, агымдагы ел, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Коръән елы дип игълан ителде. Ел башында бу уңайдан үткәреләчәк чаралар планы төзелде. Быел республика, Россия һәм дөньякүләм дәрәҗәдәге чаралар уздырылачак. Бүгенге көндә Коръән елы кысаларында алдыбызга куелган иң мөһим бурычларның берсе үтәлде - күптән түгел мөфтият тарафыннан "Казан басмасы"ның юбилей басмасы әзерләнде. Диния нәзарәте Изге Китапны 10 мең тираж белән нәшер итте.**

Республикабыз мәркәзе үзенең басма Коръәне - "Казан басмасы" белән дөнья күләмендә мәшһүр. Изге Китапның Россиягә кадәр чит илләрдә XV-XVI гасырларда ук нәшер ителә башлавы мәгълүм. Шунысы гаҗәп: аны бастыручылар мөселманнар булмаган һәм ул, нигездә, ислам дине китапларын өйрәнү, тикшерү максатыннан чыгарылган. Ә "Казан басмасы" - Россиядә басылган беренче Изге Китап, өстәвенә, Ислам дөньясында мөселманнар тарафыннан нәшер ителгән тәүге басма.

Элгәреге заманнарда гарәпләр Коръән тарихын шигъри юлларга салганнар. Ул ирекле тәрҗемә ясаганда болайрак әйтелә: "Коръән иңгән - Хиҗазда (Согуд Гарәбстаны), матур иттереп язылган - Истанбулда (Төркия), гүзәл иттереп укылган - Каһирәдә (Мисыр), мөселманнар тарафыннан беренче мәртәбә басылган - Казанда".

Ислам дине таралышында зур роль уйнаган Хиҗаз, Истанбул, Каһирә җирләре рәтендә Казанның телгә алынуы - ата-бабаларыбызның мөселманнар дөньясында мәртәбәсен тагын да ачыграк күрсәтә. "Казан басмасы" белән татар халкының типографияләрдә дини китаплар нәшер итү традициясенә нигез салына.

Бүгенге көндә үзебезнең дини асылыбызга кайту турында сөйләшүләр - менә шундый традицияләрне өйрәнү, белү, дәвам иттерү дә булып тора. Югыйсә, без традицияләрне гадәти күңел ачу чаралары итеп кенә күз алдына китерәбез. Бу - алай гына түгел. Дини китаплар басу татар халкының аңын, рухын, калебен (күңелен) нык иткән, аны төшенкелеккә бирелүдән саклаган. Һәм бу гамәлләр берничә гасыр дәвамында башкарылып килгән. Нәтиҗәдә, үзе зур бер мираска, традициягә әверелгән.





Әлбәттә, белемгә омтылган татар кешеләре элеккеге заманнарда белемне чит илләргә йөреп тә туплаган. Әмма, асылда, халкыбыз дини китапларны үзе нәшер иткән, хәтта аңа шрифтлар да эшләгән. "Казан басмасы" моңа зур дәлил булып тора. Дин әһелләре, зыялылар шул басмаларны тараткан, шул Изге Китапка таянып, күпсанлы фәнни хезмәтләр язган.

Әйтик, татарлар Петербургтагы беренче Коръән басылган типографияне Казанга кайтартуга ирешәләр. 1802 елны биредә "Иман шарты" дигән китап чыга. Аны татарлар "Татар әлифбасы" дип йөртәләр. 1803 елны икенче китап буларак ике томнан торган Коръән дөнья күрә. Әлеге Коръән ике вариантта нәшер ителә. Беренчесе - 2 томлы итеп, икенчесе пәралап (өлешләп) чыгарыла. Типография хуҗасы Габделгазиз Бурашев: "Балаларыбыз Коръән укырга өйрәнсен өчен шулай итеп бастырдык", - дип язып калдырган.

(Ахыры 4 нче биттә.)

# ДИНЕБЕЗНЕҢ КҮРСӘТКЕЧЕ – КҮРКӘМ ХОЛЫК

**Бүгенге көндә адәм балалары, мөселманнар иман күрсәткечен төрле гыйбадәтләрдә күрә. Кайберәүләр иманлы булуны - күп итеп намаз уку, икенчеләре - ураза тоту, өченчеләре - күп итеп сәдака бирү дип саный. Юк шул, намаз укуың, ураза тотуың, сәдака бирүең дә иманның күрсәткече түгел әле. Ул - бары тик Раббың каршында үз вазифаларыңны үтәү генә. Чынлыкта, кешенең күркәм холкы иман күрсәткече булып тора.**



Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйтә: "Иң камил иманлы кеше ул - иң күркәм холыклы булганыгыз", - ди. Көннәрдән бер көнне Рәсүлебез сәхабәләргә әйтә: "Кем дә кем Аллаһка вә Кыяматкә иман китергән булса, сүз сөйли икән, хәерлесен генә сөйләсен я тик торсын; кем дә кем Аллаһка вә Кыяматкә иман китергән булса, күршесенә зарар салмасын; кем дә кем Аллаһка вә Кыяматкә иман китергән булса, кунагын икърам кылсын, кадерләсен", - ди. Күрәсезме, хөрмәтле кардәшләрем, Раббыбыз иманны күркәм холык белән бәйли. Иманың булса, Раббыңның рәхмәтенә өметләнсәң, күркәм холыклы бул, начар сүз сөйләмә, кунакчыл бул, күршеңә зарар итмә, ди. Бүгенге көндә "без әһле сөннәт өммәте һәм пәйгамбәребез (сгв) шәфәгатенә өмет итәбез" дибез, шул хәдисне укуын-укыйбыз, ә бер сүзен дә гамәлгә ашырмыйбыз. Мөселманнар ислам диненең көзгесе диләр, тик нәкъ киресе дә килеп чыга. Башкаларга, күрше милләтләргә динебезнең матурлыгын, күркәм холкын күрсәтү өчен без матур сүз урынына кычкырабыз, рәнҗешкә рәнҗеш белән кайтарабыз. Безнең халкыбыз, борынгы бабаларыбыз: "Таш белән атканга аш белән ат", - дигәннәр. Хәтта гарәп халкында да элек бик матур мәкаль булган: "Әл инсән габидул ихсән (Кеше яхшылыкның колы)". Гомумән, безнең халык бөтен җирдә начарлык, катылык күреп, күнегеп беткән инде. Ул синнән дә, бәлки, үзенең каты сүзенә каты җавап көтәдер. Син шул вакытта яхшылык кылып куйсаң, каршыңда торган гафил бәндәгә йомшак сүз белән эндәшсәң, иман әһеленең күркәмлеген күрсәтсәң - ислам гадәтенең зур бер үрнәге булыр иде. Кешегә, сиңа каты итеп кылынган бәндәгә иман күзеннән карый бел, ул бит әле Аллаһның кем, Рәсүлнең кем икәнлеген белми; ул бит әле гафил, син үз үрнәгең белән Рәсүлебез шикелле кешеләргә тәрбия бирә бел. Мин мөселман дип, мәчеттә генә ятарга була ул, тик Пәйгамбәребез алай эшләдеме соң? Әлбәттә, юк. Чын Ислам, чын Пәйгамбәребез юлы ул - безгә күренгәнчә бозык, белми торган, гафил җәмгыятьтән качып яту түгел, ә шул халык арасында яшәп, аны рәнҗетмичә, кимсетмичә хикмәт белән төзәтергә, үзгәртергә тырышу.

Хәдиснең икенче кисәгендә Рәсүлебез: "Иманың булса, күршегә зарар салучы булма", - ди. Димәк, ислам дине ул - иң беренче чиратта, күршене дә рәнҗетмәү. Пәйгамбәребезнең (сгв) бик мәшһүр сорауга җавабын исебезгә төшерик әле. Берәү сорый бит: "Бер хатын бар, ул нәфел намазлар укый, нәфел уразалар тота, тик күршеләре аннан имин түгел, ул аларга зарар сала", - ди. Рәсүлебез әйтте: "Ул хатында һичбер хәерлелек юктыр, ул җәһәннәмдә".

(Ахыры 2 нче биттә.)

# ДИНЕБЕЗНЕҢ КҮРСӘТКЕЧЕ – КҮРКӘМ ХОЛЫК

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

"Ә берсе фарыз булган гыйбадәтләрен генә кыла, тик күршеләре аңардан сәламәт, имин булдылар", - дигәч, Пәйгамбәребез (сгв): "Ул - җәннәттә", - дип җавап бирде. Раббыбыз кодси хәдисендә әйтә: "Әгәр бәндәм миңа карата гөнаһ кылса, соңра үкенеп тәүбә итсә, мин аны кичерәм, әгәр икенче бер колымны рәнҗетсә, рәнҗетелгән бәндәмнән гафу сорамыйча, мин аны кичермәм", - ди. Динебезнең асыл булган максаты, ул да булса, төзек, камил җәмгыять булдыру. Димәк, кеше кешене рәнҗетмәсен, хакына кермәсен, берберләренә Аллаһның бәндәләренә кебек карауны булдырсын. Бүгенге көндә бик күп мөселманнар зарланалар: "Безне кимсетәләр, динебезне кысалар, безгә җинаятьчеләргә караган кебек карыйлар", - диләр. Бу мөселманнарга мин болай дип әйтер идем: "Безнең мәртәбәле динебез бик күркәм, камил дин булып тора. Динебездә бик күп хикмәтләр яшерелгән бит, тик без аны күрмибез генә". Раббыбыз әйтә: "Гаепне үзегездән эзләгез", - ди. Әгәр мөселман дигән кешеләр теләсә нәрсә кычкырып, дин исеменнән бозык, әшәке эшләр эшләп йөрмәсә, мөселманнарга Раббыбыз тагын да күбрәк мөмкинлекләр ачар иде. Пәйгамбәребез (сгв) дөрес әйтте бит инде: "Мөселман өммәте бер тән кебектер, берәр әгъзасы авыртса, бөтен тән яна башлый". Ниндидер бер ахмакның дин исеменнән кылган бозык гамәле нәкъ шулай безгә тәэсир итә дә инде. Хөрмәтле кардәшләрем, шуңа күрә тагын бер мәртәбә кабатлыйм: сез "мин мөселман" дип әйткәнсез икән, ул - бик зур җаваплылык. Уйламыйча кылган бозык гамәлегез динебезгә зур зарар китерергә мөмкин, шуны онытмагыз. Хәдиснең өченче өлешендә Рәсүлебез әйтә: "Кем Аллаһка вә Кыяматкә иман китерсә, кунакны каршы ала белсен", - ди. Димәк, кунакчыл булу ул - мөселманның сыйфаты. Рәсүлебез Мөхәммәд (сгв) гел Раббыбызга дога кыла торган булган: "Аллахуммә әхсәнтә халкы фә әхсин хулукы (И Аллам, син минем тышкы кыяфәтемне матур итеп яраткансың, минем холкымны да матур итеп кылсаң иде)". Шулай ук, Рәсүлебез бозык холыклы булудан сакланган вә бик еш Аллабызга бу доганы кыла торган булган: "Аллахуммә инни әгузубикә мин мункәратил әхляк (И Аллам, мин Синнән бозыклыктан саклавыңны сорыйм)". Аллабыз Пәйгамбәребезнең (сгв) догасын кабул иткән. Рәсүлебезнең холкы, дөрестән дә, барыбызга да туган көненнән алып үлеменә хәтле безгә бөтен яктан үрнәк булды. Күркәм холыклы булды. Аның холкы Коръән иде. Дөрестән дә, Аллабыз Пәйгамбәребезне (сгв) Үзе тәрбия кылды. Раббыбыз безгә дә әйтә: "Сезне дә тәрбия итәм", - ди, ә без әйтәбез: "Юк инде, кирәкми. Без үзебез беләбез, без инде - тәрбияләнгән бәндәләр", - дибез. Кайбер мөселманнар сорау бирә: "Нишләп соң Рәсүлебез бөек әхлаклы булды, ә безне Раббыбыз шундый итмәде икән?" - диләр. Аллабыз үз Китабында әйтә: "Лә икрахә фид дин (Диндә көчләү юк)". Әгәр без үзебез сорамасак, теләмәсәк, беркем дә күркәм холыкны безнең күңелләргә салмаячак. Ник соң Рәсүлебез әдәп-әхлакка бик зур игътибар бирде, безгә дә игътибарлы булырга кушты? Сәбәбе бу хәдистә: "Көннәрдән бер көнне Рәсүлебез сәхабәләрдән сорады: "Сез банкрот булган кешенең кем икәнлеген беләсезме?" - диде. Сәхабәләр: "Әйе, ул - акчасыз калган кеше", - дип җавап бирделәр. Пәйгамбәребез: "Юк. Дөрестән дә, Кыямәт көнендә банкрот булган кеше ул - уразалы, намазлы, зәкятле, гыйбадәтләр белән тулы килгән кеше булыр", - диде. Тик бер кешене рәнҗеткәне, икенче берәүнең малын алганы, өченчегә сукканы, дүртенченең гайбәтен сөйләгәне, кеше хакына керүе ачыкланыр. Бу рәнҗетелгән кешеләр Раббыбызга килеп әйтерләр: "И Аллабыз, бу кеше безне рәнҗеткән иде. Син аның гыйбадәт әҗерен безгә бир", - диярләр. Раббыбыз бу гыйбадәтле кешенең әҗерләрен гомере буе рәнҗеткән кешеләргә бирер, моның тиз арада гыйбадәтләре бетә башлар, ә рәнҗетелгән кешеләр әле һаман килә торырлар. Фәрештәләр: "Аның изге гамәлләре калмады", - дигәч, "Алай булса, безнең гөнаһларыбызны аңарга бир", - дип әйтерләр. Тиз арада гомере буена гамәл-гыйбадәт кылган бәндә бер әҗерсез калып, үзе рәнҗеткән кешеләрнең гөнаһ өеме белән харап булып, утка китәр. Менә, хөрмәтле дин кардәшләрем, нинди генә гыйбадәтләр кылма, холкың бозык булса, әдәбең булмаса, харап буласың икән. Әлбәттә, бу сүзләр: "Гомер буе әхлаклы булып гыйбадәтсез җәннәтле буласың", - дигән мәгънә бирми. Тик динебезнең күрсәткече - күркәм холык. Икенче бер хәдистә Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Вә әхыббә линнәси мә тухиббу линәфсикә тәкун муслимән (Үзеңә теләгән нәрсәне башкаларга да телә, шул вакытта син мөселман булырсың)". Бу хәдискә игътибар итсәк, Пәйгамбәребез (сгв): "Башка мөселманга, дими, башка кешегә, - ди. - Бөтен кешеләргә дә яхшылык ярат, үзеңә теләгәнне бөтенесенә теләсәң генә син Раббың алдында мөселман булырсың". Бу сүзләрнең мәгънәсе үз эченә бик зур төшенчәне ала бит. Иң күркәм җәмгыять шул була түгелме соң?

Көннәрдән беркөнне Пәйгамбәребәребез (сгв) сәхабәләргә, сорау биргән кебек итеп, сөйлисе сүзләренә игътибарлы булып, истә калдырырга куша: "Сезгә мөэмин кешенең кем икәнлеген әйтимме? - ди. - Мөэмин кешедән башкалар мал ягыннан да, үзләре ягыннан да имин булырлар. Малыбызга зарар салыр, үзебезгә дә зарар салыр дип, уйлап та карамаслар. Мөселман шул булыр: аның теленнән дә, кулыннан да башка кешеләр сәламәт булырлар. Кулы белән дә, теле белән дә безгә зарар салыр дип, мөселман турында уйлап та карамаслар". Димәк, мөселман берничек тә башкаларга зарар салмас, ди. Пәйгамбәребез (сгв) дәвам итә: "Мөҗәһид ул - Аллаһның юлында үз нәфесе белән көрәшүче булыр", - ди. Менә бүгенге көндә мөселман өммәтенең авыру, чирле булуының сәбәбе икейөзлелектә: "Җиһад!" - дип кычкырып йөриләр, ә өйләренә кайткач, я ялгыз калганда, Аллаһны онытып, мине бит беркем дә күрми дип, ни кылганнарын белмиләр. Рухи тәрбия алу дигән төшенчә, гомумән, югалып бара да инде. Пәйгамбәребез (сгв) Бәдер сугышыннан кайткач: "Кече җиһад бетте, зурысы гына калды инде", - ди. Сәхабәләр әйттеләр: "И Рәсүлебез, моңардан да зуррак җиһад була аламы инде?" Әйе, ул - үз нәфесең белән Аллабызның юлында көрәшү", - диде Мөхәммәд (сгв).

Пәйгамбәребез (сгв) дәвам итеп әйтә: "Мөҗәһид кеше - ул бозык булган эшләрдән вә гөнаһлардан китүче кеше". Бүгенге көндә мөселманнар җан төшенчәсенә карата әйтелгән сүзне бер дә дөрес аңламыйлар шул. Әгәр берәрсе: "Уку ул - энә белән кое казу", - дисә, без бит энә алып кое




казырга чыгып китмибез. Ә ник соң безнең яшьләребез: "Пакыстан кебек илләргә китәбез. Чын Ислам анда гына, монда Ислам юк", - дип, бөтенебезне кяферлектә гаепләп китеп баралар да, харап булалар. Соңра әти-әниләрен елатып, үз илләренә кайта алмыйча җәфа чигәләр. Рәсүлебез җиһадка барырга җыенган егеткә сорау бирә: "Әгәр син сугышка китсәң, әниең белән кем кала?" "Беркем дә калмый", - дигәч, Пәйгамбәребез (сгв): "Синең җиһадың - әниеңне карап, аның ризалыгын, хәер-догасын алу", - ди. Ә бүгенге көндә исә яшьлек белән әти-әниләреңнең ризалыкларын алмыйча үз илеңне ташлап китү, әлбәттә, дөрес түгел. Без, мөселманнар, һәрвакытта да үзебезне дөрес итеп тотарга тиешбез. Рәсүлебез әйтә: "Әл җәннәту тәхтә әкдәмил уммәхәт (Җәннәт әниләрнең аяк астында)", - ди.

Кыямәт көнендә үлчәүләрдә иң зур изге гамәлләрдән булганы - ул кешенең әдәпле булуы. Көннәрдән беркөнне Пәйгамбәребез Мөхәммәдтән (сгв) сорадылар: "Йә Рәсүлебез, нинди изге гамәлләр өчен кешеләр иң күп җәннәткә керер?" Ул әйтте: "Ике әйбер өчен: ул да булса, тәкъвалык вә күркәм холык (әдәпле булу) өчен". Тагын сорадылар: "Нинди гөнаһлар өчен иң күп кеше ут газабына керер?" Пәйгамбәребез (сгв) җавап бирде: "Ул ике төрле нәрсә өчен: теле (теләсә нәрсә сөйләү, әхлаксыз булу) вә җенес әгъзалары өчен", - диде.

Ислам дине ул - күркәм җәмгыять бар итәргә килгән дин. Бөтен гыйбадәт, иң беренче, Аллабыз каршындагы бурыч булса, икенче яктан, җан азыгы, рухи тәрбия булып тора.

Я Раббым, барлык мөселманнарга да күркәм холыклы булып, сөйләгән сүзләре кылган гамәлләренә туры килеп, башка милләтләргә үзебезнең күркәм холкыбыз белән үрнәк күрсәтеп, аларның күңелләрендә ислам диненә карата мәхәббәт уятып, дингә керүләренә сәбәпче булып, шул сәбәпләрнең әҗерләрен күреп, җәннәтләргә кереп, шунда мәңге калырга насыйп булса иде. Раббым, барчаларыбызга да күркәм холык бир вә бозык холыклардан сакла.

***Алмаз хәзрәт ШӘРИФУЛЛИН,***
***Татарстанның көньяк төбәге казые,***
***Чистай шәһәре һәм районы имам-мөхтәсибе***

**Габдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ:**

# "Милли спорт төрләре милләтне






**Чаллыда мөселман яшьләренең Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте кубогына татарча көрәш буенча турнирларын уздыру традициягә керде. Аның максаты - мөселман яшьләрен милли спорт төрләренә активрак тарту, аларны сәламәт яшәү рәвеше буенча башка яшьтәшләренә дә үрнәк итеп әзерләү. Быел мондый бәйге 4 нче мәртәбә узды. Ул 14 апрельдә, һәр елдагыча шәһәрнең "Витязь" спорт комплексында үткәрелде. Әйтергә кирәк, шәһәрдә мондый турнирларны югары дәрәҗәдә уздыру өчен бөтен мөмкинлекләр, шул исәптән тәҗрибәле судьялар да бар.**

Быелгы турнир Россия күләмендә игълан ителеп, күршетирә республика, өлкәләргә дә чакырулар җибәрелгән иде. Кызганыч, берничә очраклы вәкилне исәпләмәгәндә, читтән килүче спортчылар теркәлмәде. Татарстаннан читтә мөселман яшьләрен милли спорт төрләренә тарту эше йомшак куелганмы, әллә башка сәбәптәнме - монысы әлегә билгесез.

Быелгы турнирны ачу тантанасында чыгыш ясап, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов болай диде: "Динебез тормыш белән тыгыз бәйләнгән. Ул бөтен юнәлешләрне чолгап алган. Анда спортка да урын бирелгән. Ә милли спорт төрләре мөселман яшьләренең рухын, тәнен ныгыту белән

# ИСЛАМИЯТНЕҢ БӨЕК ГАЗИЗЕ

*(Ахыры. Башы газетабызның 13 апрель (№15) санында.)*

1917 елгы инкыйлабтан соң Муса Җаруллаһ Петербург вә Мәскәү мәчетләренең имам-хатыйбы булып хезмәт итә. 1926 елның май-сентябрь айларында Ризаэддин бине Фәхреддин, Габдрахман Гомәри, Кәшшафеддин Тәрҗемани, Таһир Ильяс һ.б. берлән Мәккәи-Мөкәррәмәдә гаять мәсьүлиятле вазифалы сәфәрдә була. Аның укымышлылыгы да таныла.

Әмма гыйльми хезмәтләрен нәшер итү елдан-ел кыенлаша, халык белән аралашу вә имамәтчелек вазифасын башкару юлында да, ни үкенеч-ачыныш, киртәләр көннән-көн арта бара. Җанын кая куярга белмәгәч, М.Җ.Бигиев Уфага - мөфти хәзрәтләре Р.Фәхреддин хозурына да килеп китә. Төрле сәяси күңелсезлек, рәнҗетелү-кимсетелүләр 1930 елда аны коточкыч мөһаҗирлеккә - эмиграциягә китәргә, ягъни Ватаныннан ваз кичәргә этәрәләр, мәҗбүр итәләр. Адәми зат тереклегенең түзгесез мәлләрендә дә гыйльми эшчәнлеген дәвам итә ул. 1931 елда шәхси чакыру буенча Иерусалим-Бәйтелмөкатдәстә үткәрелгән дөньякүләм мөселман конгрессында катнаша. Гомумән, Муса Җаруллаһ ул елларда киң Шәрыкның төрле якларында була. Русиягә әйләнеп кайту, газизә хатынын, балаларын күрү хыялы белән яши, аяныч ки, дәһшәтле елларда мондый мөмкинлек тамырыннан киселгән була. 1947-1948 елның кышын ул Истанбулда үткәреп, 1948 елның көзендә әл-Каһирәгә юнәлә. Саулык-сәламәтлеге какшаган (бәвел куыгы ялкынсыну, күзләрендә катаракт, йөрәк хасталыгы) Муса Җаруллаһ төрле хастаханәләрдә дәвалана. Габдрәшит казый Ибраһимның кызы Фәүзия ханым вә Галимҗан Идриси аңа ярдәм кулын сузалар: йортсыз-җирсез фәкыйрьләр, гаҗизләр йортына урнаштыралар. Шунда 1949 елның 28 октябрендә Муса Җаруллаһ Аллаһның рәхмәте белән кавыша, ягъни җан тәслим кыла, иртәгесен җеназа намазы Сәйдә Нәфисә мәсҗид шәрифендә укылып, Афифидәге Һидвия гаиләсенең падишаһ каберлегенә дәфен кылына. Кабер шәрифе безнең көннәргә килеп ирешкән, әмма багымсыз. Аллаһ ахырын хәерле кылсын.

Инде кечкенә генә чигенеш: соңгы елларда татар вакытлы матбугатында ике-өч мәртәбә: "М.Җ.Бигиев Төркия Җөмһүриятендә вафат булган", - фикере тәкъдим кылынды, әмма ул хакыйкатькә хилаф, хата. М.Җ.Бигиев гыйльми-иҗади хезмәтләренең күпчелеге дини мәсьәләләргә багышланган. Аларда ул мөкатдәс Коръәни-Кәрим, Пәйгамбәребез (сгв) хәдис шәрифләре, шәригатьнең бүгенге дөньяда тоткан урынын билгеләргә иҗтиһад кыла һәм алардан һәр заманда нәтиҗәле файдаланырга мөмкин дигән төпле фикергә килә. Шулай ук ул социаль-сәяси проблемаларны да, иҗтимагый тормыш мәсьәләләрен дә читләтеп үтми.

Гыйльми-иҗади эшчәнлегенең тәүге адымнарында ук ул Габдрәшит Ибраһимов берлән бергә "Ислам социализмы" концепциясен эшкәртә вә ислами тәгълиматның яңа җәмгыять төзүгә каршы түгеллеген дәлилләмәле исбатлый. Ул Шәрык илләрендә хатын-кызларга ирләр белән бертигез хокуклар вә ирек бирергә кирәклегенә басым ясап күрсәтә. Коръәни-Кәрим тарихы буенча мәшгулиятьләрен ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итә, һәм бу хәл аны 1915 елда ук Казанда дөнья күргән Каләми Шәриф басмасында хаталар барлыгын тануга китерә. Ошбу ачыш җирле галим-голәмә аркасында зур шау-шу кузгата. "Рәхмәте Илаһия гомуми" (Казан, 1910) исемле китабында мөәллиф-Мосхәф Шәриф аять-кәримәләренә таянып, "Аллаһның рәхмәте киң булуы", мөселманнарның гына түгел, башкаларның да җәннәткә керү мөмкинлеге турында сүз алып бара. Мәгълүм булсын: бу хезмәткә Ризаэддин бине Фәхреддиннең рецензиясе бар, вә Муса Җаруллаһның матбугатта пәйда булган җавабы да нәшер ителгән. Галимнең 1912 елда Казанда нәшер ителгән "Озын көннәрдә рузә" исемле күләмле хезмәте дин-исламның мөһим нигезләреннән булган мәсьәләләрне яктыртуга багышланган. Биредә ул җәйге эссе көннәрдә ислам кануннарына хилафлык китерми хезмәт адәменең хәлен җиңеләйтү максатын күз уңаенда тота. Бу очракта ул хасталарга, мосафирларга һәм бала имезүче хатыннарга карата Каләмулладагы аять-җәлиләләргә таяна. Дин вә дини тәгълиматка кагылышлы мәсьәләләр Муса Бигиевның "Тасхихе рәсме хат Коръән" (Казан, 1919), "Инсаннарның гакыйдәи Илаһияләренә бер нәзар" (Ырынбур, 1911) һ.б. хезмәтләрендә дә чагылыш таба. Ә "Шәригать әсаслары" (Казан, 1907), "Кавагыйде фикъһия" (Казан, 1910), "Зәкят" (Петербург, 1916), "Халык нәзаренә берничә мәсьәлә" (Казан, 1912), "Зәбихә һәм хатын" (Петербург, 1914), "Маидә" (Петербург, 1914) һәм "Мәет якмак мәсьәләсе" (Петербург, 1914) кебек хезмәтләрендә М.Бигиев әдәп-әхлак вә хокук мәсьәләләренә туктала.

Актив җәмәгать эшлеклесе булган галимнең күп кенә хезмәтләре татарлар арасында иҗтимагый хәрәкәтләрне, милләт тормышындагы мөһим вакыйгаларны, сәяси агымнарны барлауга багышланган. Ошбулар арасында "Исляхат әсаслары" (Петроград, 1916), "Хокукы әсасия" (Петроград, 1916), "Мөляхазә" (Петербург, 1914), "Мөселман нәдвәсе" (Казан, 1906) кебек әсәрләре үзләренең көн кадагына сугулары берлән аерылып торалар. Мөтәфәккирнең "Исламият әлифбасы" (Берлин, 1923) дигән хезмәте дә югарыда күрсәтелгәннәр белән аваздаш. Биредә Муса Җаруллаһ татар иҗтимагый фикере үсешен күздән кичерә вә ислам берлеге идеясен яклап чыга.

Олуг галимебез Муса Бигиевның рухы шат булса иде! Кабере нурдан мәхрүм булмасын.

**Равил ҮТӘБАЙ-КӘРИМИ,**
**Шәркыят вә Исламият галиме**

# Дини мәгариф системасында мәдрәсә мөгаллиме эшчәнлегенең үзенчәлекләре

Татар халкы дөнья күләмендә үзен тырыш һәм булдыклы, максатчан һәм белемле, дини һәм әдәпле милләт буларак таныткан. Тарихтан мәгълүм булганча, югары мәдәниятле халык буларак формалашыр өчен татарларга ислам дине ярдәм иткән: дөрестән дә, милләтебезнең үсеш юлы, мең еллык гыйбрәтле тарихы нәкъ менә шушы дин белән бәйле. Бабаларыбызның укымышлы булулары, гарәп графикасы нигезендә укый-яза белүләре дә - мөселман дин әһелләре эшчәнлегенең нәтиҗәсе.

Шулай итеп, мәдрәсәләр элек-электән татар мәгариф системасының нигез ташын тәшкил итте. Ә мәдрәсәдә белем бирүче остаз-мөгаллим җирле халык арасында аерым бер хөрмәткә, олылауга лаек кеше булып саналды. Татарлар элек-электән гыйлемгә омтылып, аның кадерен белеп яшәгәннәр һәм әйтергә кирәк, дөньяви, гомуми белем нигезендә дин гыйлеме булган: аның ярдәмендә милләттәшләребез рухияткә тартылган, ислам дине аша дөньякүләм мәдәнияткә катнаштырылган. Нәкъ менә шуңа күрә татарларда мәдрәсә мөгаллиме махсус статуска ия булган: ул күп кешеләрнең күңелен белем нуры белән яктырткан, милли мәдәният, югары әхлак үрнәге булып торган. Мәдрәсәләр, анда хезмәт итүче хәлфәләр җәмгыять һәм аерым кеше тормышына зур йогынты ясый алган. Моның сәбәбе - мөгаллимнәрнең киң кырлы белемгә дә, күркәм әхлакый сыйфатларга да ия булуы.

1917 елгы социалистик инкыйлабыннан соң 8 дистәләп елны үз эченә алган дәвердә мәдрәсәләр эшчәнлеге билгеле сәбәпләр аркасында туктатылып торды. XX гасырның 90 нчы елларында исә татар дини мәгариф системасы янә аякка баса башлады. Бер-бер артлы мәдрәсәләр ачыла килде һәм, әлбәттә инде, кадрлар мәсьәләсе - дин белеме эзләп килгән шәкертләргә тиешле дәрәҗәдә гыйлем-тәрбия бирерлек мөгаллимнәр табу үтә дә мөһим бер проблемага әверелде. Һәркем үзенчә тырышты, яңа шартларга яраклашып, туган мөмкинлекләрне файдаланып, хезмәт итте. Татарстанның шактый күп төбәкләрендә эшли башлаган мәдрәсәләрдә башлап йөрүчеләр сыйфатында ихласлы энтузиастлар булды. Алар башкарган эшнең асылы "без нинди дер яңа нәрсә оештыру юлында түгел, ә үз асылыбызга кайту юлында" дигән принциптан гыйбарәт иде.

Шулай итеп, элгәре эшләгән мәдрәсәләр, анда хезмәт иткән мөдәррисләр XX гасыр ахырында оеша башлаган дини уку йортлары, яңа заман мөгаллим-остазлары өчен күркәм вә гыйбрәтле үрнәк булды. Йөз ел элек милли мәгариф системасында хезмәт иткән дин әһелләре бүгенге көндә үрнәк итеп алырлык нинди сыйфатларга ия иде соң? Һәммәбезгә мәгълүм, татарлар элек-электән башка милләт, башка дин вәкилләре арасында яшәде. Шулай ук, гарәп илләрендә яшәүче халыклардан аермалы буларак, татарларга дин тотмаучы милләттәшләре белән аралашып, тыгыз элемтәдә торып гомер кичерергә туры килде. Шуңа күрә дә мәдрәсәдә белем алучы шәкертләрне остазлары ислам дине, шәригать буенча яшәми торган җәмгыять шартларында эш итә алырлык итеп әзерләде. Бүгенге көндә дә мәдрәсәләр, ислам дине һәм дөньяви дәүләт үзара гармонияле рәвештә мөгамәлә корырга тиешлеген истә тотып шәкертләрне укытырга тиеш. Халкыбызның дини мәгариф системасында иҗтиһад кылган мәшһүр тарихи персонажларның эшчәнлегенә игътибар итсәк, шунысы ачыклана: алар беркайчан да дини фанатиклар тәрбияләүне максат итеп куймады, киресенчә, мәдрәсә укучыларына дини булмаган мохиттә яшәргә һәм хезмәт итәргә кирәк булачагын "сеңдерде". Аларның шушы тәҗрибәсе хәзерге вакытта да заманча дини мәгариф системасын төзүдә, без яшәгән дәүләттә динебезне уңышлы үстерү юнәлешендә бик тә файдалы була ала.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# саклап калырга ярдәм итә"

бергә, милләтебезне саклап калу өчен дә үз өлешен кертә".

Чаллы шәһәре башкарма комитеты рәисе Фәрхәт Латыйпов, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев та котлау чыгышларында мөселман яшьләрен спорт белән активрак шөгыльләнергә чакырды.

Быелгы бәйгедә Татарстанның 21 шәһәр-районыннан һәм Россия ислам университетыннан 75 көрәшче катнашты. Алар арасында 8 спорт мастеры да бар иде. Ә Әлмәт командасы тулаем спорт мастерларыннан гына торды. Үлчәнүгә кадәр спортчылар намаз гыйбадәте тәртипләрен белү-белмәүләре турында тест биремнәре эшләде. Чөнки, турнир үтә башлаганнан бирле, анда намаз укучылар гына катнаша ала. Тәртип шундый. Көрәш 60, 70, 80, 90, 100 килограмм һәм аннан да авыррак үлчәү категорияләрендә барды. Көрәшчеләр киеренке, әмма матур көрәш күрсәтте. Быелгы турнирда травма алучыларның булмавы көрәш техникасының камилләшә баруын күрсәтә. Кискен көрәштә үз үлчәү авырлыкларында түбәндәге көрәшчеләр батыр калды: 60 килога кадәрге үлчәү категориясендә - Чаллының 52 нче мәктәп укучысы Муса Камалов, 70 килога кадәрге ү.к. - Әлмәттән спорт мастеры Руслан Нургалиев, 80 килога кадәрге ү.к. - КФУның Алабуга институтында белем алучы I курс студенты Айназ Фәләхов, 90 килога кадәрге ү.к. - Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институтының IV курс студенты Айвар Билалов, 100 килога кадәрге ү.к. - Әлмәттән нефтьче Фәнил Минһаҗев, 100 килодан авыррак ү.к. - "Елховнефть" идарәсе хезмәткәре, спорт мастеры Ильяс Галимов.




Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: 2010 ел турнирында олуг бүләккә ия булган Фәнил Минһаҗев турнирны ачу тантанасында үзенең уңышлы хаҗ кылуы турында хәбәр итте, Коръән укыды һәм көрәшчеләргә уңышлар теләде. Шулай ук турнирда беренче елны хаҗ юлламасына ия булучы Илдар Алтынбаев та ("Таттрансгаз"ның Азнакай бүлекчәсе хезмәткәре) көч сынашты һәм 100 килодан артык үлчәү категориясендә II (призлы) урын яулады.

Көрәш тәмамлангач, батырлар арасында җирәбә салынды һәм анда отучы 19 яшьлек Айназ Фәләхов турнирның иң олы бүләге - хаҗга юлламага ия булды. Аны яшь көрәшчегә Җәлил хәзрәт тапшырды. II һәм III (призлы) урыннарны Чаллы, Азнакай, Минзәлә, Түбән Кама, Әлмәт, Актаныш, Саба көрәшчеләре бүлеште. Җиңүчеләргә Диния нәзарәте дипломнары һәм бүләкләр тапшырылды. Командалар арасында җиңүче итеп Чаллы көрәшчеләре танылды. II һәм III урыннарда - Әлмәт һәм Азнакай командалары.

Турнир матур бер бәйрәмгә әверелде. Тик, нигәдер, мөселман яшьләре көрәшен тамаша итүчеләр аз була. Ә бит, уйлап карасаң, турнирны карап утыру вакытында гына да үзеңә күпме көч, энергия аласың, ял итәсең.

Әлбәттә, мондый бәйгеләрне оештыру зур чыгымнар таләп итә. Быелгы бәйге иганәчеләре - РФнең "Татарча көрәш" милли спорт федерациясе, Диния нәзарәте, мөхтәсибәтләр, Чаллының уннан артык предприятие-җәмгыятьләре *(анда хезмәт куючы җитәкчеләрнең күбесе үзләре дә элеккеге көрәшчеләр).*

**Хәлил ШӘРИФ,**
**Чаллы мөхтәсибәтенең**
**матбугат үзәге җитәкчесе**

# Дини мәгариф системасында мәдрәсә мөгаллиме эшчәнлегенең үзенчәлекләре

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Әйе, һәр дин әһеле, ә мәдрәсә мөгаллиме бигрәк тә, заман сулышын яхшы тоеп яшәргә һәм эшләргә тиеш. Дөнья бик үзгәрүчән. Тормыш безнең алдыбызга яңадан-яңа сораулар, проблемелар куя, аларга - телисеңме, теләмисеңме - җаваплар табарга туры килә. Мәдрәсә мөгаллимнәре төрле тормыш мәсьәләләрен ислам тәгълиматы "күзлеге" аша хәл итәргә, ягъни шәригать кысаларында калып, урталык тарафдары булырга һәм моңа шәкертләрне дә өйрәтергә тиеш.

Бүгенге мөселман өммәтенә хас булган күренеш - ул төрледән-төрле секталарның, ислам динен, дин әһелләрен дискредитацияләгән агымнарның пәйда булуы. Кызганычка, бүген яшьләр, шул исәптән белем юлында булган кайбер шәкертләр дә, шундый секта-агымнарга җәлеп ителә. Бу чын-чынлап хәзерге заман мөселманнары өчен кыен бер проблемага әверелде. Традицион исламнан читләшеп, шикле бер төркемгә кушылган яшь кеше, гадәттә, үз амбицияләрен, нәфес теләкләрен җиңел юл белән канәгатьләндерергә омтыла, динне үзенең максималистик карашларын тормышка ашыру мөмкинлеге буларак файдаланырга тели. Бу нисбәттә мәдрәсәләр төптән уйланган, белем вә гыйбрәтле мисаллар белән ныгытылган сәясәт алып барырга тиеш. Кызганычка, кайбер дини уку йортларында бу мәсьәләгә тиешле дәрәҗәдә игътибар бирелмәде. Шәкертләр, төпле дини белем ала, әмма гомуми укымышлылык җитенкерәми. Нәтиҗәдә яшь дин әһеле: "Менә аять! Менә хәдис!", - дип кычкырып үзенекен тәкърарлый, ә татар менталитеты, милли үзенчәлекләр, халык белән аралаша алу, диндә беренче адымнарын гына ясаучы кешенең психологиясен белү, сөйләшә һәм тыңлый белү, ягъни сабыр булып һәм әдәплелек саклап, тыныч, хикмәтле итеп дискуссия алып бару кебек нәрсәләр читтә кала. Татар дин әһелен әзерләү процессында мәдрәсәләр шушы мәсьәләләргә, һичшиксез, зур игътибар бирергә тиеш. Шәкертләрдә үз халкыңа карата хөрмәт һәм горурлык хисе тәрбияләргә кирәк. Аның өчен татарлар тарихын, гыйбрәтле, бөек үткәнен өйрәнү мәслихәт. Яшьләр милләт тарихын өйрәнмәсә, белмәсә, үз халкы язмышына да, үзе яшәгән җирлектәге ислам дине үсешенә дә битараф булачак. Тарихны белмичә торып, кеше үз халкы белән горурлана алмый. Ә безнең тарихыбыз - ул Ислам. Бабаларыбыз тормышын өйрәнү иманыбызны ныгытачак кына. Үз халкың белән горурлану исә милли үзаң уянуга этәргеч булачак, ә бу - халкыбызга хас булган барлык уңай сыйфатларны үзеңдә тупларга, тәрбияләргә ярдәм итәчәк. Бүгенге җәмгыять тормышында, шул исәптән мәдрәсәләр эшчәнлегендә дә, әлеге факторга игътибар булмау аркасында татарлар үз милли үзенчәлеген, телен, гореф-гадәтләрен югалта бара. Ә бит уйлап карасаң, Аллаһы Тәгалә безне татар итеп яраткан һәм безнең бурычыбыз - иман белән бергә милли йөзебезне дә кадерләп саклау. Бу - безнең өстебездәге әһәмиятле әманәт һәм дини уку йортлары эшчәнлеге дә миллилекне саклап калу мәсьәләсендә гаять зур роль уйный. Кызганыч ки, бүген мәдрәсәләр гарәп теленә, гомумән, дини белемгә басым ясап, милләт, халык мәсьәләсен кайгыртырга ашыкмый кебек.

Тарихыбызга мөрәҗәгать итеп, XIX гасыр дәвамында - XX гасыр башында эшләгән мәдрәсәләрне, анда эшләүче мөгаллим-остазларны искә аласым килә. Зыяэддин Камали, Әхмәтһади Максуди, Габдулла Апанаев, Шәмсетдин Күлтәси, Галимҗан Баруди һәм башкалар сыйфатлы һәм шул ук вакытта гади, халыкка да аңлаешлы булган дини һәм фәнни эчтәлекле китаплар, методик кулланмалар язган. Әйтик, XIX гасырда татар халкының күренекле дин әһеле, мәдрәсә хәлфәсе Җамалетдин Бикташи дөньяви дәүләттә яшәүче гади татар кешеләре өчен һәркем үзенең туган телендә аңларлык дини китаплар, язмалар чыгарган. Хәтта Р.Фәхреддин дә аны "бөтен Русия мөселманнары остазы" дип атаган. Шулай итеп, элгәре зыялыларыбыз беркайчан да "диндә милләт юк" дигән шигарь-лозунгны күтәреп чыкмады, киресенчә - ихластан, зур тырышлык белән үз милләте өчен хезмәт итте.

Мәдрәсә мөгаллиме эшчәнлегенең үзенчәлекләре турында әйткәндә, әлбәттә инде, дин өлкәсендә эшләүче укытучыга хас булырга тиешле сыйфатларны да искә алмыйча булмый. Иң беренче мөһим сыйфат буларак - үз эшең, укыткан шәкертләрең өчен тирәнтен җаваплылык хисен тою кебек сыйфатны билгеләп үтәсем килә. Икенчедән, эшнең нәтиҗәсе өчен ихластан кайгыру (ничек итеп үз өең, үз гаиләң, үз балаларың өчен кайгырсаң, шундый ук дәрәҗәдә (ә бәлки аннан да артыграк!) динең өчен, мәдрәсәң һәм шәкертләрең өчен кайгыру булырга тиеш). Шулай ук эш сөючәнлек, үзенә карата таләпчәнлек, рухи һәм бәдәни пөхтәлек, сабырлык, намуслылык һәм әдәплелек - мәдрәсә мөгаллиме өчен бик тә кирәкле сыйфатлар. Иң мөһиме - дини остаз укучылар-шәкертләр алдында гына түгел, гади халык - туганнары, күршеләре, танышлары арасында да динебездә телгә алына торган югары әхлакый сыйфатларның гәүдәләнеше булуын онытмаска тиеш. Бу уңайдан бер кызыклы очрак, мәзәк дәрәҗәсендә булган тормыштагы бер хәл искә төшә. Авыл мулласы өе янындагы киртәсен рәтләп кадак кага икән. Күрше егете моны зур игътибар белән күзәтә. Шактый гына вакыт узгач, мулла күрше егеткә дәшә: "Нәрсә карап торасың шундый дикъкать белән, әллә кадак какканны күргәнең юкмы?" Моңа җавап итеп егет әйтә: "Күргәнем бар, әмма шунысы кызык: чүкеч белән бармагыңа суккач, нәрсә әйтерсең микән? Шуны көтеп, күзәтеп торам мин сине".

Мәзәк итеп сөйләрлек хәл булса да, монда уйланырлык нәрсә бар, җәмәгать. Чыннан да, без - дин әһелләре, имамнар, мөгаллимнәр - халкыбызның игътибарлы күзәтүе астында. Безгә карап, күп кеше динебез хакында фикер йөртә, нәтиҗәләр ясый. Аларның дин юлына басулары, бу дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булулары безнең эшчәнлеккә, безнең тырышлыкка һәм ихласлыкка да бәйле. Ләкин шунысы да бик әһәмиятле: без барыбыз да Аллаһ Раббыбыз күзәтүе астында. Әгәр Аның динен, Аның бөек Канунын башкаларга җиткерергә алынганбыз икән - димәк, өстебезгә бик зур җаваплылык алдык. Шушы җаваплы эшне һәммәбезгә дә лаеклы башкарып чыгарга язсын. Аллаһы Тәгаләнең динен халкыбызга җиткерергә, пәйгамбәребез Мәхәммәд (сгв) үрнәгендә гамәл кылырга, барчабызга да Аллаһ рәхмәтендә булырга насыйп әйләсен.



*Фото иллюстрация рәвешендә бирелә.*

***Ришат КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе директоры***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ясту намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 21.04.12 | 3:53 | 5:23 | 13:02 | 17:43 | 20:03 | 21:33 |
| Якшәмбе | 22.04.12 | 3:51 | 5:21 | 13:02 | 17:44 | 20:05 | 21:35 |
| Дүшәмбе | 23.04.12 | 3:49 | 5:19 | 13:02 | 17:45 | 20:07 | 21:37 |
| Сишәмбе | 24.04.12 | 3:46 | 5:16 | 13:02 | 17:47 | 20:09 | 21:39 |
| Чәршәмбе | 25.04.12 | 3:44 | 5:14 | 13:02 | 17:48 | 20:11 | 21:41 |
| Пәнҗешәмбе | 26.04.12 | 3:41 | 5:11 | 13:02 | 17:49 | 20:13 | 21:43 |
| Җомга | 27.04.12 | 3:39 | 5:09 | 13:02 | 17:50 | 20:14 | 21:44 |
| Шимбә | 28.04.12 | 3:37 | 5:07 | 13:02 | 17:51 | 20:16 | 21:46 |

## "Казан басмасы"

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Революциядән соң татарларда дини китап басу традициясе бөтенләй диярлек өзелә. Гарәп графикалы өем-өем китапларны яндырып юкка чыгарганда татарларның китап басу традициясе балта белән чабыла. 70 елдан артык вакыт эчендә бөтен совет иленә Изге Китап бер-ике тапкыр гына нәшер ителә.

Үзгәртеп корулардан соң, кибетләр дини китаплар белән тулды. Изге китаплар төрле мөселман илләреннән алып кайтып сатылды яки бүләккә өләшенде. Шул ук вакытта, Казанның 1000 еллыгын үткәргән көннәрдә Кол Шәриф мәчете ачылышына "Казан басмасы" "мемориал басма" буларак дөнья күрде.

Бүгенге көндә без татар халкының дини китаплар нәшер итү традициясен кире кайтарырга, яңартырга омтылабыз. Шул максаттан, нәзарәт көче белән китаплар нәшер ителә. "Казан басмасы"н бастыру бу юнәлештә җитди эш алып барылуын күрсәтә. Хәзерге вакытта Диния нәзарәте "Мөгаллим сәни" китабын басмага әзерли. Коръәнне укырга өйрәтә торган китап озакламый дөнья күрәчәк.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары***
***Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

## Төзәтү

**Газетабызның 2012 ел, 13 апрель санында (№15) дөнья күргән "Исламиятнең бөек газизе" дип исемләнгән мәкаләнең башында сүз Муса Бигиев турында барды. 1 нче биттә без галимнең фотосын урнаштырдык. Тик техник сәбәпләр аркасында фото астындагы сүзләрдә ялгышлык киткән. Җибәрелгән хатабыз өчен барлык укучыларыбыздан да гафу үтенәбез.**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №16 (133) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-530.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 19 апрель көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**